**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«27» мая 2024г.** **№ 71**

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 12 сентябрендәге 529 номерлы «Теләче муниципаль районы Гражданнар оборонасы идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

МКУ «Теләче муниципаль районы Гражданнар оборонасы идарәсе»нең 2024 елның 20 маендагы 60-24-ИН номерлы хатын карап, «Теләче муниципаль районы Гражданнар оборонасы идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү системасын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 10 маендагы 315 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган Граждан оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр төзегәндә исәпкә алына торган су объектларында кешеләрнең янгын куркынычсызлыгын һәм иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү методикасына үзгәреш кертү турында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 12 сентябрендәге 529 номерлы «Теләче муниципаль районы Гражданнар оборонасы идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» карарына (31.01.2018 № 62, от 27.10.2020 № 461, от 08.10.2022 № 194 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган «Теләче муниципаль районы Гражданнар оборонасы идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

- 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. «Теләче муниципаль районы Гражданлык яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары:

| № т/б | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи окладның күләме (сум) |
|---|---|---|
| 1. | Учреждение җитәкчесе | 25 014 |
| 2. | Оператив дежур | 19 242» |

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Җитәкче урынбасары – Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге башлыгы Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин